Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Хансөяр авылында
2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында.
2022 елның 18 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлеге Хансөяр авылында гражданнар җыены нигезендә

Карар:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлеге Хансөяр авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидлардан тыш, үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Хансөяр авылы зират коймасын ремонтлау;
- кышкы чорда Хансөяр авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту .

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә), Баулы муниципаль районы сайтында бастырырга ( http://bavly.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ___________ З. С. Галләметдинов